СОВЕТ
БОЛЬШЕАКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР АКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

с. Большая Акса

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль 2021 ел №5/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турындагы «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында " 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Советының 27.02.2020 ел, № 60/1 карары (03.06.202020 ел, № 64/2, 13.11.2020ел, № 3/2 редакциясендә) белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр не кртергә:

**6 статьяның 22 пунктында** «хезмәт кенәгәсе" сүзләреннән соң "(булган очракта)» дигән сүзләр өстәргә;

**13 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасында** «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр " сүзләрен өстәргә»;

**20 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасын** түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге

белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә кергән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көнендә үз көченә керә.

Зур Аксу авыл
җирлеге Башлыгы: А.В.Храмов